| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>СРЕДНЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>УРТА ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2020 с. Средние Тиганы № 126

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлегендә Бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре системасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатларында

**Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлегендә Бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә 2015 елның 26 гыйнварындагы 130-1 номерлы, түбәндәге эчтәлекле:
- 13 маддәнең 16 пунктында «акчаларны исәпкә алу буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 30 маддәнең 2 пунктындагы 2 абзасында «кассадагы» сүзен «казначылыктагы» сүзенә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны Урта Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы**
**вазыйфаларын башкаручы,**
**Советта рәислек итүче** **Э.М.Камалова**